**Государственное автономное**
**профессиональное образовательное учреждение**
**«Мамадышский политехнический колледж»**
(ГАПОУ «Мамадышский ПК»)

УТВЕРЖДАЮ

Заместитель директора по ТО

_____________ Файзреева В.В.

«5» апреля 2022 г.

**РАБОЧАЯ ПРОГРАММА УЧЕБНОЙ ДИСЦИПЛИНЫ**

ОУД. 12 Родной язык

по специальности

09.02.01 Компьютерные системы и комплексы

2022 г.

Рабочая программа учебной дисциплины составлена на основе: «Рекомендаций по организации получения среднего общего образования в пределах освоения образовательных программ среднего профессионального образования на базе основного общего образования с учетом требований федеральных государственных образовательных стандартов и получаемой профессии или специальности среднего профессионального образования», рекомендованных Департаментом государственной политики в сфере подготовки рабочих кадров и дополнительного профессионального образования Министерства образования и науки Российской Федерации, письмо директора Департамента Н.М. Золотаревой от 17.03.2015 № 06-259

| | |
|---|---|
| Обсуждена и одобрена на заседании предметно-цикловой комиссии: преподавателей общих гуманитарных и социально-экономических дисциплин | Протокол №1<br>«5» апреля 2022 г.<br>Председатель ПЦК: ________/Л.В.Ямалиева/<br>(подпись, инициалы фамилия) |

Разработчик: Ахметшина Айгуль Дамировна, преподаватель

**ЭЧТӘЛЕК**

**УКУ ФӘНЕНЕҢ ЭШ ПРОГРАММАСЫ ПАСПОРТЫ............................4**

**УКУ ДИСЦИПЛИНАСЫНЫҢ ЭЧТӘЛЕГЕ ҺӘМ СТРУКТУРАСЫ.................................................................................... 8**

**УКУ ФӘНЕН ТОРМЫШКА АШЫРУ ШАРТЛАРЫ............................. 16**

**УКУ ФӘНЕН ҮЗЛӘШТЕРҮНЕ ТИКШЕРҮ ҺӘМ БӘЯЛӘҮ............... 17**

## 1.Уку фәненең эш программасы паспорты
## “Туган тел”

### 1.1. Программаны куллану өлкәсе

«Туган тел» укыту дисциплинасының эш программасы төп һөнәри белем бирү программасының бер өлеше булып 09.02.01 Компьютер системалары һәм комплекслары белгечлеге буенча урта һөнәри белем бирү федераль дәүләт белем бирү стандартлары нигезендә 09.00.00 Мәгълүмат һәм исәпләү техникасы белгечлекләре төркеменә керә торган социаль тәэминатны оештыру тора.

### 1.2. Төп һөнәри белем бирү программасы структурасында дисциплина урыны:

"Туган тел" укыту дисциплинасы ОПОПның гомуми белем циклына керә.

Көллияттә татар теленә гуманитар предметлар рәтеннән беренчел дәрәҗәдәге әһәмият бирелә, ул ана телендә укытыла торган башка фәннәрне өйрәнү теле дә, укучыларның рухи дөньясын, әхлагын формалаштыруда әһәмиятле чара да. Ана теле ярдәмендә укучылар буыннар тәҗрибәсе белән тупланган мәдәният һәм сәнгать кыйммәтләре белән таныша, алардагы уңай сыйфатларны үзләштерә, укучыда туган җиренә мәхәббәт хисе тәрбияләнә.

Тел дәресләрендә, сүз сәнгате буларак, әдәби әсәрне аңлау һәм кабул итү дәрәҗәсе камилләшә. Татар теле дәресләрендә рус телен, чит ил телләрен өйрәнүгә дә нигез салына. Татар теле дәресләрендә танып белү, фикерләү сәләтен үстерүгә зур игътибар бирелә. Укучыларның акыл һәм иҗади сәләтләрен үстерү тәэмин ителә, хәтерләре һәм күзаллау дәрәҗәсе яхшыра, гомуми караш даирәсе үстерелә, мөстәкыйль уку эшчәнлеге күнекмәләре формалаша. Төрле белемнәрне үзләштерү һәм саклау

формасы буларак, татар теле көллияттә укытыла торган башка предметлар белән тыгыз бәйләнештә тора һәм аларны үзләштерү сыйфатына уңай тәэсир итә.

**1.3. Дисциплинаның максатлары һәм бурычлары - дисциплинаны үзләштерү нәтиҗәләренә карата таләпләр:**

«Туган тел» укыту дисциплинасының эчтәлеген үзләштерү студентлар тарафыннан түбәндәге нәтиҗәләргә ирешүне тәэмин итә:

- укучыларның сүзлек байлыгын арттыру, сөйләм һәм язма телен үстерү белән беррәттән, рухи дөньясын баету, реаль чынбарлыкка дөрес караш формалаштыру, тормыш вакыйгаларына хәбәрдарлыгын тәэмин итү;
- татар теленнән алынган теоретик материалны (тел системасын) аңлап үзләштерүне һәм тел фәнен яхшы белүне тәэмин итү;
-гамәли тел материалларын хәтердә калдырып һәм тәрбияви максатны күздә тоткан хәлдә, изложение һәм сочинениеләрне логик фикерләп, телдәге сурәтләү чараларын дөрес һәм урынлы кулланып, грамоталы итеп һәм дөрес каллиграфия белән яза белүләренә ирешү;
- идея дәрәҗәсенең югары булуын тәэмин итү;
-текст өстендә эшләү күнекмәләрен камилләштерү, үзеңнең һәм иптәшләреңнең кылган гамәлләренә дөрес бәя бирү;
- информация чыганакларыннан кирәкле мәгълүматларны таба һәм куллана белергә өйрәтү;
-укучыларда дәреслек һәм өстәмә әдәбияттан (әдәби әсәрләре, фәнни чыганаклар, төрле сүзлекләр, вакытлы матбугат) дөрес файдалану күнекмәләрен үстерү;
- план, тезис, конспектлар төзү, эш кәгазьләрен (деловые бумаги) дөрес һәм грамоталы язарга өйрәтү;
- бәйләнешле сөйләм культурасын үстерү өчен, укучыларда укыганны һәм сөйләгәнне кабул итү, сөйләмнән урынлы файдалану осталыгын

(уку,язу,сөйләү,тыңлау, аңлау, сөйләшү, аралашу, диалогик һәм монологик сөйләм) иҗади эш башкару күнекмәләрен формалаштыру һәм үстерү.

**Белем дәрәҗәсе таләпләре:**

Укучыларның үзләштерергә тиешле белем – күнекмәләре:

1. Фонетика, лексика тармаклары турында, сузыкларга һәм тартыкларга хас орфоэпик һәм орфографик нормаларны белү, аваз үзгәрешләренә аңлатма бирә белү.

2. Татар теленең сүзлек составын белү. Лексикография буенча тулы мәгълүмат бирә белү.

3. Сүз төзелеше, сүз ясалышы, кушымчалар турындагы белемнәрне ныгыту.

4. Сүз төркемнәре. Синтаксис буенча тулы мәгълүмат алу.

5. Язу тарихын тирән белү.

Сөйләм эшчәнлегенә таләпләр:

1. Орфография, орфоэпия нормаларын үзләштерү, фонетик анализ ясый белү.

2. Төрле сүзлекләрдән файдалану күнекмәләрен булдыру.

3. Сөйләмдә сүз төркемнәреннән дөрес һәм урынлы файдалану, төгәл итеп анализлау

4. Сүзләргә фонетик, морфологик, синтаксик анализ ясый белү күнекмәләрен булдыру, анализ үрнәкләрен камил белү.

5. Сүз ясалышын, төзелешен, сүзтезмәләрне тикшерү үрнәкләрен камил белү.

6. Орфографик прициплар һәм аларның нормаларын белү.

7. Стилистика һәм сөйләм культурасы нормаларын төгәл белү.

8. Пунктуация кагыйдәләреннән дөрес файдалану.

9. Сөйләм эшчәнлеге буенча тулы мәгълүматлы булу.

1**.4. Программаны үзләштерү өчен уку дисциплинасының сәгатьләр саны:**

Максималь уку йөкләнеше: **117** с.

Укучыларга максималь укыту йөкләмәсе – **78 с.**

Укучының аудиторлы укыту (мәҗбүри уку дәресләре) – **78 с.**

уку шул исәптән лаборатория һәм практик дәресләр – **0 с.**

Укучыларның мөстәкыйль эше – 39 с.

**Аттестация ДИФ. ЗАЧЕТ формасында.**

# 2. Уку дисциплинасының эчтәлеге һәм структурасы

## 2.1 Уку дисциплинасының эчтәлеге һәм структурасы
## Туган тел

| Укыту эшләре төре | Сәгать саны |
|---|---|
| Максималь уку йөкләнеше: | **117** |
| Укучыларга максималь укыту йөкләмәсе | **78** |
| Укучының аудиторлы укыту (мәҗбүри уку дәресләре) | 78 |
| уку шул исәптән лаборатория һәм практик дәресләр | 0 |
| Укучыларның мөстәкыйль эше | **39** |
| **Йомгаклау аттестациясе – Диф. Зачет.** | |

# 3. Уку программасынның эчтәлеге

| Бүлекләр һәм темалар исемлеге | Укыту материалының эчтәлеге, практик эш, укучыларның үзлектән эше | Үткәрелгән вакыты (сәг.) | Үзләш. дәрәҗәсе |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| **1нче бүлек** | **Тел – аралашу чарасы, иҗтимагый һәм сәяси күренеш** | **10** | 2 |
| | Тел гыйлеме турында төшенчә. Тел гыйлеменә өйрәтә торган фәннәр.<br>Телнең төп функцияләре<br>Дөнядагы телләр, аларны төркемләү<br>Дөньядагы телләр арасында татар теленең тоткан урыны<br>Телдән сөйләм<br>Язма сөйләм<br>Практик эш: күнегүләр эшләү | 7 | |
| | **Тикшерү эше:** Кереш тикшерүе. №1 Диктант | 1 | |
| | **Укучыларның үзлектән эше**: Тел - аңлашу,аралашу чарасы,иҗтимагый,сәяси күренеш .Татарлар яши торган төбәкләр. | **2** | |
| **2 бүлек** | **Фонетика.** | **9** | 2 |
| | **Авазлар һәм хәрефләр.**<br>**Тартык һәм сузык авазлар.**<br>**Аваз үзгәрешләре** | **6** | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | Сингармонизм законы<br>Графика, орфография<br>Сүзләргә фонетик- график анализ ясау тәртибе<br>**Укучыларның үзлектән эше:** Сузыклар һәм тартыклар ассимиляциясе. Рәт гармониясе. Орфография,орфоэпия бүлеге буенча күнегүләр эшләү | **3** | |
| **3нче бүлек** | **Лексика** | **10** | |
| | Синонимнар,антонимнар.<br>**Куп мэгнэле сузлэр.Фразеология.**<br>**Татар теленен сузлек составы. Омонимнар.** | 3 | |
| | **Тикшерү эше:** Диктант. | 1 | |
| | Этимология турында төшенчә. Калькалар<br>Лексикография | 2 | |
| | **Тикшерү эше:** "Лексикология" бүлеген йомгаклау. Контроль эш | 1 | |
| | **Укучыларның үзлектән эше:** Охшаш яңгырашлы сүзләр. Искергән сүзләр,тарихи һәм яңа сүзләр.Диалекталь сүзләр**.** | **3** | |
| **4 нче бүлек** | **Морфология** | | |
| | **Исем** | **8** | |
| | Исемнәрнең берлек һәм күплек саны. Исемнәрнең килеш белән төрләнеше.<br><br>Исемнәрнең тартым белән төрләнеше.Ялгызлык, уртак- лык исемнәр. | 3 | 2 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | Исем сүз төркеменә морфологик анализ | | |
| | **Укучыларның үзлектән эше**: Исемнәрнең ясалышы ягыннан төрләре. Исемнәрдә иркәләү һәм кечерәйтү кушымчалары.Исемнәрнең килеш белән төрләнүе. | **5** | |
| | **Сыйфат** | **2** | |
| | Сыйфатларның ясалышы . Сыйфат дәрәҗәләре.<br><br>Исемләшкән сыйфатлар. Сыйфат сүз төркеменә морфологик анализ. | 2 | 2 |
| | | | |
| | **Сан** | **4** | |
| | Саннарның ясалышы. Сан төркемчәләре.<br>Сан сүз төркеменә морфологик анализ.<br><br>**Укучыларның үзлектән эше:** Санның грамматик билгеләре.Саннарның дөрес язылышы. | 2<br><br><br>**2** | 2 |
| | | | |
| | **Алмашлык** | **4** | |
| | Алмашлыклар.<br>Алмашлык сүз төркеменә морфологик анализ.<br><br>**Укучыларның үзлектән эше:** Юклык алмашлыклары. Алмашлыкларда басым. | 2<br><br><br>**2** | 2 |
| | **Фигыль** | 26 | 2 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | Затланышлы фигыльләр<br>Затланышсыз фигыльләр<br>Фигыль төркемчәләре, юнәлешләре<br>Фигыльләрдә зат-сан категориясе<br>Фигыльләрдә заман категориясе. Контроль эш.<br>Фигыль дәрәҗәләре<br>Фигыльләргә морфологик анализ ясау. | 7 | |
| | **Тикшерү эше:Изложение** | 2 | |
| | **Укучыларның үзлектән эше:** Аналитик фигыльләр. Ярдәмче фигыльләр.Фигыль формаларында басым.Татар газетасына күзәтү ясарга.Күптән үткән заман.Казан шәһәре турында язарга.Музейга баруыгыз турында язарга.Фигыльләрдә инкар итү категориясе. Фигыльләрнең төрләнми торган формалары.Хәл фигыль. Фигыльләрдә мәгънәви төркемчәләр. | **17** | |
| | **Рәвеш** | **5** | |
| | Рәвеш. Рәвеш төркемчәләре.<br>Рәвеш сүз төркеменә морфологик анализ ясау | 2 | 2 |
| | **Тикшерү эше:** “Сүз төркемнәре” темасына контроль эш. Тестлар. | 1 | |
| | **Укучыларның үзлектән эше:** Сыйфат һәм рәвешләрне аеру.Рәвеш һәм сыйфатларның ясалышы | **2** | |
| **5 нче бүлек** | **Синтаксис** | | |
| | **Җөмләдә сүзләр бәйләнеше** | **7** | |
| | Тезүле бәйләнешне белдерүче чаралар. | **3** | 2 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | Ияртүле бәйләнешне белдерүче чаралар.<br>Сүзтезмә һәм тезмә сүз. | | |
| | **Тикшерү эше.** | 1 | |
| | **Укучыларның үзлектән эше:** Аналитик фигыльләр кулланып үзеңнең һөнәреңне белән бәйләп текст төзергә.Бер әсәрдән өзек күчереп язарга һәм аналитик фигыльләрнең төркемнәрен билгеләргә. | **3** | |
| **7 нче бүлек** | **Гади җөмлә** | **5** | |
| | Хаталар өстендә эш. Җөмлә.<br>Җөмләнең баш кисәкләре. Ия.<br>Җөмләнең баш кисәкләре.Хәбәр.<br>Ия белән хәбәрнең ярашуы.<br>Ия белән хәбәр арасында сызык кую очраклары. | **5** | 2 |
| | | | |
| **8 нче бүлек** | **Җөмләнең иярчен кисәкләре** | **12** | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | Җөмләнең иярчен кисәкләре-аергыч<br>Җөмләнең иярчен кисәкләре-тәмамлыклар<br>Җөмләнең иярчен кисәкләре-вакыт,урын хәлләре<br>Җөмләнең иярчен кисәкләре-сәбәп хәле<br>Җөмләнең иярчен кисәкләре-максат хәле<br>Җөмләнең иярчен кисәкләре- рәвеш хәле<br>Җөмләнең иярчен кисәкләре-күләм хәле<br>Җөмләнең иярчен кисәкләре-шарт хәле<br>Җөмләнең иярчен кисәкләре-кире хәл<br>Аныклагычлар<br>Аныклагычлар янында тыныш билгеләре | **11** | |
| | **Тикшерү эше:** Диктант. | 1 | |
| **9 нчы бүлек** | **Җөмләнең модаль кисәкләре** | **5** | |
| | Хаталар өстендә эш. Кереш сүзләр.<br>Җөмләнең модаль кисәкләре-эндәш сүзләр | 3 | 2 |
| | **Тикшерү эше**: изложение | 2 | |
| | | | |
| **10 нче бүлек** | **Кушма җөмлә** | **10** | 2 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | Тезмә кушма җөмләләр<br>Иярченле кушма җөмләләр<br>Иярчен җөмләләрнең мәгънә ягыннан төрләре.<br>Иярчен ия җөмлә .<br>Иярчен хәбәр җөмлә.<br>Иярчен аергыч җөмлә.<br><br>**Тикшерү эше**: Контроль диктант<br>Хаталар өстендә эш. | 8<br><br><br><br><br><br>1 | |
| | **Тикшерү эше: Бүлекне йомгаклау тестлары. Диф. Зачет.** | **1** | |
| | | | |
| | **Барлыгы:** | **117 с.** | |

## 4. Уку фәнен тормышка ашыру шартлары

### 4.1. Минималь материаль – техник тәэмин ителешкә таләпләр

Фән программасы тормышка ашыру кабинет булуны таләп итә: тел белеме кабинеты.

Уку кабинетының җаһазлары: язу тактасы, кием шкафы, китап шкафы, өстәл (укучылар өчен), өстәл (укытучылар өчен), урындыклар.

**Укыту кабинетының җиһазы:**

- утырту урыннары - укучылар саны буенча;
- укытучының эш урыны;
- укыту-күргәзмә әсбаплар комплекты.

**Белем бирүнең техник чаралары:**

- Интерактив комплект (Инв. № 222101045615);
- Портатив ПЭВМ RAYbook Bi1010 ICL ( Инв. № 222101045648).

## Кулланылган әдәбият

**Студентлар өчен:**

1. Татар теле: рус телендә урта гомуми белем бирү оешмалары өчен уку әсбабы (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) 10 нчы с-ф. - Р.К. Сәгъдиева. - Казан: “Мәгариф – Вакыт” нәшр., 2018. - 247 б.
2. Татар теле: рус телендә урта гомуми белем бирү оешмалары өчен уку әсбабы (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) 11 нчы с-ф. - Р.К. Сәгъдиева. - Казан: “Мәгариф – Вакыт” нәшр., 2018. - 286 б.

## 5.Туган тел фәнен үзләштерүнең нәтиҗәсен тикшерү һәм бәяләү

| Укыту нәтиҗәсе<br>( белергә, эшләргә тиеш) | Уку нәтиҗәләрен тикшерү һәм бәяләү формалары һәм алымнары |
|---|---|
| **Укучыларның үзләштерергә тиешле белем – күнекмәләре:**<br>1. Фонетика, лексика тармаклары турында, сузыкларга һәм тартыкларга хас орфоэпик һәм орфографик нормаларны белү, аваз үзгәрешләренә аңлатма бирә белү.<br>2. Татар теленең сүзлек составын белү. Лексикография буенча тулы мәгълүмат бирә белү.<br>3. Сүз төзелеше, сүз ясалышы, кушымчалар турындагы белемнәрне ныгыту.<br>4. Сүз төркемнәре. Синтаксис буенча тулы мәгълүмат алу.<br>5. Язу тарихын тирән белү.<br>**Сөйләм эшчәнлегенә таләпләр:**<br>1. Орфография, орфоэпия нормаларын үзләштерү, фонетик анализ ясый белү.<br>2. Төрле сүзлекләрдән файдалану күнекмәләрен булдыру.<br>3. Сөйләмдә сүз төркемнәреннән дөрес һәм урынлы файдалану, төгәл итеп анализлау<br>4. Сүзләргә фонетик, морфологик, синтаксик анализ ясый белү күнекмәләрен булдыру, анализ үрнәкләрен камил белү.<br>5. Сүз ясалышын, төзелешен, сүзтезмәләрне тикшерү үрнәкләрен камил белү.<br>6. Орфографик прициплар һәм аларның нормаларын белү.<br>7. Стилистика һәм сөйләм культурасы нормаларын төгәл белү.<br>8. Пунктуация кагыйдәләреннән дөрес файдалану. | Изложение; диктант; тестлар; реферат; сорауларга җавап бирү; күнегүләр эшләү; конспектлар төзү; тәрҗемә итү; |